**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ АПАС МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ ДӘВЕШ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ**

# КАРАРЫ

**12 октябрь 2018 ел №109**

**Татарстан Республикасы Апас муниципаль районы Дәвеш авыл җирлеге Советының "Физик затларның мөлкәтенә налог турында" карарга үзгәрешләр кертү хакында**

Россия Федерациясе Җир кодексы нигезендә ,"Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында" 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 40 нчы статьясы нигезендә Татарстан Республикасы Апас муниципаль районы Дәвеш авыл җирлеге Советы карар итте:

1.Татарстан Республикасы Апас муниципаль районы Дәвеш авыл җирлеге Советының 2014 елның 14 ноябрендәге 75 номерлы " Физик затларның мөлкәтенә налог турында" карарына түбәндәге үзгәрешләр кертергә:

2нче пунктта

а) 1 пунктчаның икенче абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

"гаражларга һәм машина урыннарына, шул исәптән әлеге пунктның 4.1 пунктчасында күрсәтелгән салым салу объектларына;"

б) 2 пунктчаның икенче абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

"фатирларга, фатир өлешләренә;"

в) 3 пунктчаның икенче абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

"торак йортларга, торак йортларның өлешләренә;"

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасының хокукый мәгълүматлар Рәсми порталында һәм Татарстан Республикасы Апас муниципаль районы Дәвеш авыл җирлеге Уставта каралган тәртип буенча авыл җирлегенең максус мәгълүмат стендларында бастырып чыгарырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны авыл җирлеге Башлыгына йөкләргә.

**Җирлек башлыгы Т.Т.Хөсәенов**